СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

_____________№_____________

На № 4218 от 27.08.2020

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертүне раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы беренче өлеше 20 пункты, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 30-32 статьялары, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге генераль планына үзгәрешләр кертү проектына 2020 елның 17 августындагы 10-53/10217 номерлы Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В. Песошин кул куйган бәяләмә нигезендә, 2020 елның 19 августында уздырылган халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча һәм Биклән авыл җирлеге Советының 2020 елның 20 августындагы 39/1 номерлы «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге генераль планына үзгәрешләр кертү» проектын килештерү турында» карарын исәпкә алып, район уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертүне расларга.
2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль район
Башлыгы урынбасары

Р.И. Закиров